ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Карар
№ 15

Постановление
«28» июль, 2025 ел.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге Башкарма комитетының
02.03.2023 елның 26 санлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 ел, № 2314 санлы «Гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булмаган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыкларын тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру кагыйдәләрен раслау турындагы" (2024 нче елның 14 мартында керткән үзгәрешләр белән) карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы "Ишки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урынын (урынын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 02.03.2023 ел, №26 карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә ».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат

стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Мамадыш муниципаль районының "Интернет"мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче: Р.К.Хафизов